Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Кубас авыл җирлегенең Кубас авылындагы
гражданнар җыены

# КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлеге составына керүче Кубас авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 27 ноябре №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлегенең Кубас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунтлау һәм грейдированиеләү, вак таш җәю), килешү буенча эшләр өчен түләү

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 384 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 235 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«**РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 235 катнашучысы тавыш бирде;

**«**КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлегенең Кубас авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлегенең Кубас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунтлау һәм грейдированиеләү, вак таш җәю), килешү буенча эшләр өчен түләү.

3. Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлегенең Кубас авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлегенең Кубас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш,

300 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунтлау һәм грейдированиеләү, вак таш җәю), килешү буенча эшләр өчен түләү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Кубас авыл җирлеге
башлыгы ________________ Н.С. Логинова